**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«13» март 2025ел** **№ 44**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре филиаллары эшчәнлеген туктату турында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» нең 2025 елның 10 мартындагы 97 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Граждан кодексының 57, 58 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 11 ноябрендәге 449 номерлы карары белән расланган Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның төрләрен үзгәртү һәм бетерү тәртибенә таянып, 2025 елның 4 мартындагы җыелыш беркетмәләре белән танышып, муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен тотуга чыгымнарны оптимальләштерү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 01 сентябреннән эшчәнлекне туктатырга:

1.1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Фатыйх Хөсни исемендәге Олы Мәтәскә урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе филиалы - “Лесной поселогы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе”.

1.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркеме.

2. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нә (Карпова Н.В.), МКУ «Теләче муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтериясе»нә (Дәүләтшина Г.М.), әлеге карарның 1 пунктының 1.1-1.2 пунктчаларында күрсәтелгән гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чара нәтиҗәсендә азат ителүче хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктының 1.1-1.2 пунктчаларында күрсәтелгән гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарның 1 пунктының 1.1-1.2 пунктчаларында күрсәтелгән гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә (Сөнгатуллин М.М., Йосыпова С.Г.), юридик затларның бердәм дәүләт реестрында үзгәрешләрне теркәгәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга, әлеге максатларда кирәкле гаризаларны һәм башка документларны имзаларга, законнарда каралган тәртиптә һәм срокларда башка гамәлләр һәм рәсмиләштерүләрне башкарырга вәкаләтле булырга.

5. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин